РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

06.09.2021 ел № 20

Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен (кушымта итеп бирелгән) расларга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының «Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 22 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык Р.Р. Гарипов

Каенлы авыл җирлеге Советының
«Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан
Түбән Кама муниципаль районы бюджетына
башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибен раслау турында»
2021 елның 6 сентябрендәге 20 номерлы карарына
кушымта

Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Каенлы авыл җирлеге (алга таба – җирлек) бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары нигезендә эшләнгән һәм Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү очракларын һәм тәртибен билгели.

## 2. Башка бюджетара трансфертлар бирү очраклары

Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

1) төзелгән килешүләр нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы дәрәҗәсенә тапшырганда гамәлгә ашыру өчен;

2) көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны финанс белән тәэмин итүгә, шулай ук җирлекнең башкарма комитеты (алга таба - «җирлек башкарма комитеты») тарафыннан расланган резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибендә каралган башка чараларга;

3) бюджет турында карарда каралган башка максатларга.

## 3. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары һәм тәртибе

1. Бюджетара трансфертлар бюджет ассигнованиеләре һәм күрсәтелгән максатларга бюджет турындагы карарда каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2. Әлеге Карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең баш бүлүчесе булып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге башкарма комитеты тора.

3. Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертларны бүлү бюджет турындагы карар белән раслана.

4. Бюджетара трансфертлар бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе җирлек башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район башкарма комитеты) арасында төзелгән килешүләр

белән билгеләнә.

5. Бюджетара трансфертлар бирү әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 1 пункты нигезендә җирлек башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында РФ Бюджет кодексының 142.5 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 пункты нигезендә төзелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 2-3 пунктлары нигезендә бюджетара трансфертлар бирү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

6.1 Башка бюджетара трансфертлар бирү җирлек башкарма комитеты карары нигезендә һәм җирлек башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты төзегән килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.2 Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мәсьәләне карау өчен район башкарма комитеты җитәкчесе җирлек башкарма комитеты җитәкчесенә, аларны файдалану күздә тотылган максатларны һәм соралган сумманы раслаучы исәп-хисапларны күрсәтеп, финанс чаралары бүлеп бирү турында дәлилләнгән мөрәҗәгать җибәрә.

6.3 Район башкарма комитеты җитәкчесенең район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мөрәҗәгате җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан мөрәҗәгать алынганнан соң 10 көн эчендә карала.

6.4. Җирлек башкарма комитеты карары һәм Килешү нигезендә җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр керткәннән соң, җирлек Түбән Кама муниципаль районы бюджетына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетларга касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган территориаль органы счетына бюджет ассигнованиеләрен күчерүне башкара.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, район башкарма комитеты җитәкчесенә, карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, җирлекнең дәлилләнгән язмача баш тартуы җибәрелә.

## 4. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану өчен җаваплылык һәм контроль

1. Бюджетара трансфертлар бирү максатлары яки шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар җирлек бюджеты кеременә биш банк көне эчендә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә җирлек башкарма комитетының язма таләбе буенча күчерелергә тиеш.

2. Бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган бюджетара трансфертлар калдыгы, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, җирлек бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

3. Башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән акчаларны Килешүдә каралмаган максатларда тоту рөхсәт ителми.

4. Җирле үзидарә органнары башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.